**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » 02 2020 № 83

Аксубаево

Торак секторда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында

РФ Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә торак фондта янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләрен бозуларны профилактикалау чараларын оештыру (“Торак-2020” операциясе) турында" 2020 елның 24 гыйнварындагы 65/31 номерлы боерыгы нигезендә һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, Аксубай муниципаль районы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән превентив чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәкъдим итәргә:

1.1. Авыл җирлекләре башлыкларына:

- торак фондта һәм торак пунктларда янгын-профилактика эшен үткәрүне күздә тоткан тиешле норматив хокукый актлар кабул итәргә;
- ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның, притоннарның, имин булмаган һәм күп балалы гаиләләрнең яшәү урынын исәпкә алырга һәм контрольгә алырга;
- янгын-профилактика эшен оештыруны, яшәү урыны буенча гражданнарны көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне, халык арасында агитация материалларын әзерләү һәм таратуны, аз керемле гражданнарга мич җылыту һәм электр үткәргечләрне ремонтлау буенча социаль ярдәм күрсәтүне, шулай ук башка янгын-профилактик чаралар үткәрүне оештырырга.
- максатчан пропаганда чараларын үткәрүне активлаштырырга; балалар арасында янгыннарны кисәтү буенча тәрбия эшен көчәйтергә; мәктәпләрдә янгынга каршы темаларга әңгәмәләр үткәрергә;
- РКЭБ (Районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге) Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары һәм полициянең участок уполномоченныйлары белән берлектә ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар, имин булмаган һәм аз керемле гаиләләр, өлкән

яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар, шулай ук социаль адаптацияләнмәгән гражданнар, спиртлы эчемлекләр кулланучыларның яшәү урыннары тикшерергә;

1.2.Россия Эчке эшләр министрлыгының Аксубай муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы И. И. Алмакаевка:

- ЭЭМның Аксубай районы буенча бүлегенең участок уполномоченныйлары хезмәткәрләренең "Торак-2020" күзәтү-профилактика операциясендә катнашуын тәэмин итәргә. Хезмәт күрсәтә торган территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы чараларын халык арасында пропагандалау һәм агитацияләү эшен активлаштырырга;
- социаль җайлашмаган гражданнарның, спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклар белән мавыккан затларның, күп балалы гаиләләрнең һәм билгеле бер яшәү урыны булмаган кешеләрнең яшәү урыннарын тикшерүне оештырырга.
- күпфатирлы торак йортларның чирма һәм подвал биналарын тикшерү өчен Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча РКЭБ хезмәткәрләре һәм торак оешмаларының вазыйфаи затлары белән уртак рейдлар үткәрүдә катнашырга;

1.3. Аксубай янгын-коткару гарнизоны җитәкчесе эчке хезмәт капитаны Р. М. Ибляминовка (102 ПСЧ "11 ПСО ФПС ГПС ГУ МЧС РФ по РТ"):

- торак пунктларда янгын-профилактика эшен үткәрү өчен Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтнең аерым постларын, ВДПО инструкторларын (Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте) эшкә җигәргә;
- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында ТР Аксубай муниципаль районы торак пунктларының торак фондында янгын куркынычсызлыгы торышы турындагы мәсьәләне карау турында тәкъдимнәр кертергә.
- район җитәкчелеге катнашында узган киңәшмәләрдә районның торак йортларында янгын куркынычсызлыгы торышы турында фикер алышырга.

1.4. Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча РКЭБ җитәкчесе урынбасарына Р. Х. Гафиятовка:

- янгын частеның шәхси составы һәм торак фондны профилактик тикшерүдә катнашкан затлар белән дәресләр оештырырга һәм үткәрергә;
- Дәүләт янгын күзәтчелеге органнарына федераль законнар тарафыннан бирелгән чараларны тулысынча кабул итеп, барлык дәүләт, ведомство һәм шәхси торак йортларны, идарәче компания хезмәт күрсәтә торган күп фатирлы йортларны тикшерергә.
- Барлык профилактик төркемнәргә ярдәм күрсәтергә.
- Барлык хисап материалларын һәм проблемалы мәсьәләләрне кичекмәстән районның (гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы буенча Комиссия) ГХ ЯКК рәисенә хәбәр итәргә.

1.5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Нежность" халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге дәүләт бюджет учреждениесе директоры Т. А. Габдрахмановага:

- социаль хезмәткәрләрне, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга хезмәт күрсәтүче, янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау, хезмәт күрсәтүче йортларда, картлар, күп балалы, исәптә торучы кешеләрдә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча чараларда катнашырга.

1.6. Аксубай газ участогы өлкән мастеры А. Г. Золинга:

- газ приборларының торышын тикшергәндә газ хезмәте хезмәткәрләре белән янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә игътибар итәргә; торак фондта янгыннарны кисәтү буенча пропаганда һәм агитация эшләре үткәрергә.
- "Торак фонды мониторингы" программасы кысаларында ЙЭГҖ (йорт эчендәге газ җиһазлары) файдалануга килешү төзегән идарә компанияләренә мониторинг үткәрергә һәм аларны реестрга кертергә;
-Аксубай муниципаль районы территориясендә җир һәм төзелеш эшләрен башкаручы оешмалар тарафыннан ордерлар һәм белешмә-килешүләрнең шартларын үтәүне, ЙЭГҖ системасы һәм аның аерым элементлары торышын тикшергәндә газүткәргечләрнең сакланышын тәэмин итү өчен, контрольдә тотуны тәэмин итәргә,
- газ белән тәэмин итүче оешма һәм идарәче оешма арасындагы килешү нигезендә махсуслаштырылган оешмалар белән ЙЭГҖ техник хезмәт күрсәтүне үткәрергә.

1.7. "Аксубай штп идарәче компаниясе" ҖЧҖ җитәкчесе Р. В. Сафиуллинга:
- капиталь һәм агымдагы ремонт кысаларында янгынга каршы чараларны үтәүгә өстәмә акча җыю мәсьәләсе буенча күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең гомуми җыелышларын оештырырга;
- яшәү урыны буенча гражданнарны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне оештырырга, белешмәлекләр тарату белән;
- Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча РКЭБ күрсәтмәләрен тулысынча үтәүгә ирешергә.

1.8. Барлык район җитәкчеләренә:
- үз кул астындагылар арасында көнкүрештә һәм эш урыннарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү турында агитация эшен оештырырга.
- тышкы һәм эчке янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын эшкә яраклы хәлгә китерергә.
- Биналарга, корылмаларга һәм су чыганакларына керү юлларын һәм подъездларны чистартырга.

1.9. “Авыл таңнары” район газетасы баш мөхәррире Л. В. Жареновага:
- районның «Авыл таңнары» газетасында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны яктыртуны оештырырга.

2. Профилактик төркемнәрнең барлык җитәкчеләренә ай саен 25 сан буенча хисап материалларын Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча РКЭБка хисап формалаштыру өчен җибәрергә.

3. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 гыйнварындагы «Район территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» гы 18 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: А. Ф. Горбунов